КАРАР

№ 2 «28» ноябрь 2024 ел

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Иске Маҗын авыл җирлегенең Гришкино торак пунктында 2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Иске Маҗын авыл җирлегенең Гришкино торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Иске Маҗын авыл җирлеге Гришкино торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда үзара салым чараларын 3500 сум күләмендә кертергә, 1 һәм 2 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучылары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары, көндезге формада белем алучы студентлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, күпбалалы гаиләләр, сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучылар, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган, СВО катнашучылары һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Гришкино торак пунктында торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (асфальт валчыкны сатып алу, ташу, асфальт ватыклары белән салу, эшләр өчен шартнамә буенча түләү);

3. Әлеге карарны Иске Маҗын авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Минзәлә муниципаль районы сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://menzelinsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми сайтында http://pravo.tatarstan кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче: ____________________ Э.Р.Шәймәрданов

ТР Минзәлә муниципаль районы
Иске Маҗын авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе ____________________ Э.Р.Шәймәрданов
(имза)